ГЛАВА
МАЛЬБАГУШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ МӘЛБАГЫШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ул. Джалиля,д.2, с.Мальбагуш,
Азнакаевский муниципальный район
423330

Җәлил ур., 2 нче йорт, Мәлбагыш авылы,
Азнакай муниципаль районы, 423330

Тел./факс(885592)9-00-04; E-mail:Malb.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«05» ноябрь 2025 ел № 6

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлегенең Каменка торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар итәм:

1. Гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлегенең Мәлбагыш торак пунктында теркәлгән, сайлау хокукына ия булган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Мәлбагыш авыл җирлегенең Мәлбагыш торак пунктында 2025 елның 17 ноябрендә гражданнар җыенын үткәрергә.
2. Билгеләргә:
- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлегенең Каменка торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп -Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитетын;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты- 2025 елның 17 ноябрендә 10.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр;
– гражданнар җыенын уздыру урыны- Каменка авылы, Җәлил ур, 2
3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:
- 2025 елның 05 ноябреннән дә соңга калмыйча, гражданнарга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитетында түбәндәге адрес буенча гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын тәэмин итәргә: Мәлбагыш авылы, Җәлил урамы, 2 һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәлбагыш авыл җирлегендә түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында: Мәлбагыш авылы, Җәлил ур., 2 йорт ; Түбән Якый авылында, Кашапов ур., 23 йорт (Фельдшер-акушерлык пункты), Каменка авылы, Җәлил урамы, 1;

- сайлау хокукына ия  Каменка  торак пунктында яшәүчеләрнең исемлекләрен төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Мәлбагыш  торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән гражданнар җыены турында хәбәр итәргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

Сез "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш  авыл җирлегенең Мәлбагыш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, кендезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы?

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор ечен запас частьләр сатып алу)

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» http://aznakaevo.tatar.ru., Мәлбагыш  авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан: Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Мәлбагыш авылы, Җәлил ур, 2 ( «Мәллә " иҗтимагый-мәдәни үзәге бинасы), Түбән Якый авылында, Кашапов ур., 23 йорт (Фельдшер-акушерлык пункты), Каменка авылы, Җәлил урамы, 1 мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан кененнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башлык: А.Ю. Әхмәтшин